калеб хозурлыгы белән уку, боргаланмау, чит сүзләр сөйләшмәү.

6. Доганы үзең генә ишетерлек, башкалар ишетмәслек итеп уку.

7. Дога укыганда авызың чиста булу, начар ис килмәү.

8. Мөхәммәд галәйһиссәләмнән ишетелгән догаларны уку, белмәгән чит сүзләр кыстырмау.

9. Дога укыганда кулларыңны күкрәк турысына кадәр күтәреп ачып тоту.

10. Доганы ахырынача уку, бүлгәләмәү.

11. Дога беткәч, куллар белән йөзне сыпырып, "Әмин" дию.

**Дога үрнәге**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Әлхәмдү-лилләһи Раббил галәмиин. Вәссаләәтү-вәссәләәмү галәә сәййидинә мөхәммәдиү вә галә әәлиһии вә әсхә-әбиһии әҗмәгыйиин.

Йә, Раббым! Кылган намазларымны, гыйбадәтләремне хата-ялгышлардан гафу итеп, кабул ит!

Шуннан соң Аллаһыдан ни теләкләр, үтенечләр бар - шуларны сорарга, Хак Тәгаләгә ялварырга кирәк. Ни телисең, нилләрдән сакланасың, нилләрдән котыласың килә – бөтен теләкләрне теләп, доганы тәмамлаганнан соң: "Әмин! Йә, Раббым! Догаларымны кабул әйлә!" – диелә һәм "Сөбеханә Раббикә Раббил-гыиййзәти гаммә ясифүүн вә сәләмүн галәл-мүрсәлин. Вәлхәмдү лилләһи Раббилгаләмиин", – догасы укыла.

*("Татар дини календаре"ннан)*

# Гөнаһ теләкне җиңү

Рухый остаз булып саналган Ибраһим ибн Әдһәм янына күңеле гөнаһ эшләү теләге белән янган бер кеше килә.

– Әй, Ибраһим ибн Әдһәм әфәнде, гөнаһлар эшләргә миңа рөхсәт бир яисә күңелемне гөнаһлы фикерләрдән арындыра торган нәсыйхәтләр бир, – дип мөрәҗәгать итә әлеге бәндә.

– Сиңа гөнаһ эшләргә рөхсәт бирәм, әгәр дә Аллаһы Тәгаләнең ризыкларын ашамасаң, – дип җавап бирә хәзрәт.

– Мин моны һич тә булдыра алмыйм, чөнки ашамыйча яши алмыйм, – ди гөнаһ эшләргә теләүче.

– Аллаһы Тәгаләнең суларын эчмә.

– Ничек инде, мин сусыз яши алыйм. Моны һич тә булдыра алмам.

– Аллаһы Тәгалә бар иткән һаваны сулама.

– Тәнемдәге һәрбер күзәнәгем һавага мохтаҗ. Мин һавасыз яши алмыйм.

– Аллаһы Тәгалә бар иткән һәм син атлап йөри торган җир өстен ташлап чыгып кит.

– Җир өстендә мин тудым, җир өстендә үлеп, аңа кире керәчәкмен. Ничек мин җирне ташлап, каядыр китә алыйм?

– Гөнаһны эшләргә теләсәң, Аллаһыдан кач һәм Ул сине күрмәгән бер җирдә гөнаһ эшлә.

– Аллаһы Тәгалә һәр әйберне һәр җирдә күреп тора һәм күңел эчебездә булган бөтен уйларыбызны да белеп тора. Мин Аңардан берничек тә кача алмыйм.

– Үлем фәрештәсе синең җаныңны алырга килгәндә: «Мин әле үләргә җыенмыйм. Бар, кит минем янымнан», – дип әҗәлеңне куып җибәрә алсаң, сиңа гөнаһ эшләргә рөхсәт итәм.

– Башына килгән әҗәлдән бер генә кеше дә котыла алмады. Мин дә үлемне берничек кичектерә алмыйм.

– Аллаһы Тәгалә ризыгын ашамыйча, суларын эчмичә, һавасын суламыйча торып, Аллаһы Тәгалә яраткан җирне ташлап китә алмыйча торып, килгән әҗәлеңне кире борып җибәрә алмыйча торып, ничек итеп син миннән гөнаһ эшләргә рөхсәт сорыйсың?! Бу сүзләрне аңла, күңелең сеңдер, үз өстеңдә эшлә һәм Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметеңне өзмә.

Изге Коръән китабында Аллаһы Тәгалә әйтә: *«Әй, гөнаһ эшләп, үзләренә зарар итүче бәндәләрем! Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чынлыкта Аллаһы Тәгалә бөтен гөнаһларны гафу итә. Ул - гафу итүче һәм рәхимле».*

Хөрмәтле дустым! Шуны бел: гөнаһ эшләргә этәрүче фикерләр кайвакыт гөнаһның үзеннән дә, аны эшләгәнгә караганда да кешегә күбрәк борчу һәм авырлык китерә. Гөнаһлы фикерләрдән күңелне пакьләр өчен, «ярамый, ярамый, ярамый», дигән сүзне кабатлап торып кына чистарынып булмый. «Ярамый» дигән коры сүз белән генә күңелдә кабынып киткән гөнаһлы фикерләрне сүндереп бетерү читен. «Ярамый» дип гөнаһтан тыелырга тырышкан бәндә зур гына учакны өреп сүндерергә теләгән кешегә охшап кала. «Юк, юк, ярамый» дип өрелгән гөнаһ учагы тагы да күбрәк янып таралачак. Гөнаһны нигә эшләргә ярамаганлыгын белмичә торып, аның ахыргы нәтиҗәсен күрмичә, ачысын татымыйча торып, тыелырга тырышкан кешеләргә карагыз. Алар ахыр чиктә гөнаһның колы булып, хайваннардан да түбәнрәк дәрәҗәләргә төшеп, гөнаһлар учагында янып, кешелекләрен көлгә әйләндерәләр. Гөнаһлы фикерләрдән күңелен пакьләргә теләгән кеше гөнаһларга сәбәп булган күренешләрдән мөмкин кадәр ерак торып, гөнаһ эшләүдән читләшергә тиеш. Авырмаган кеше берәрсе белән күрешеп-очрашып, грипп вирусын йоктырмаса, чирләп китә алмаган кебек, күңелендә гөнаһ фикерләре булмаган кеше берәр кайдан яисә берәр кемнән гөнаһ фикерен бирүче инфекция эләктермәсә, берничек тә күңелендә андый уй була алмый. Күңелендә уянган гөнаһлы фикерләрен тормышка ашырса, кеше аларның нинди нәтиҗәгә китерәчәген күзалларга тиеш. Чөнки нинди генә гөнаһны алсаң да, аның ахыргы нәтиҗәсе, һичшиксез, үкенечле бетә. һәм һәрбер гөнаһ «орлыгы» беренче карашка матур булып күренсә дә, әгәр дә ул «орлык» чәчелсә, аның җимешләре әче, чәнечкеле була. Гөнаһ агачында өлгергән кайбер җимешләрне әйтеп китү кирәк. Аларның кайберләре үкенечле күз яшьләреннән тора, кайберләре – авырудан, кайберләре – якын кешеңне югалтудан, кайберләре – канга батудан,кайберләре – утта янудан, кайберләре кешене тынычсыз, хәсрәтле



түенчә, әгәр татуировка хупланмаган ысул белән, ягъни дәвалану өчен түгел, ә башка максатларда ясалса да, аннан ут ярдәмендә арыну мәҗбүри түгел. Янәсе, бу нәҗес кичерелә һәм андый татуировка белән намаз уку рөхсәт ителә.

Ш ә ф и г ы й мәзһәбе галимнәре фикеренчә, әгәр тән тиресенә тәяммүм ясау таләп ителерлек зыян салынмаган икән, татуировкадан арыну мәҗбүри. Ниндидер бер куркыныч булганда, татуировканы бетерү мәҗбүри түгел һәм тәүбәгә килгән очракта, кеше моның өчен гөнаһлы саналмый. Бу татуировка балигъ булган затка аның үз ризалыгы белән ясалган очракка карый. Әгәр ул балигъ булганчы яки аның үз ризалыгыннан башка ясалган икән, татуировканы бетерү мәҗбүри түгел. Аның намазы дөрес санала, һәм ул да намазда имам була ала.

**Рәшит ИДЕЛЛЕ.**

*("Дин вә йола" газетасыннан)*

# Тулы бәхет

Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә Коръәндә әйтте: *«Аллаһы сезгә җирне файдаланып тору өчен халык кылды, вә күкне бөек түбә ясады, вә үзегезне күркәм сурәт белән сурәтләде, вә сезне тәмле пакь ризыклар белән ризыкландырды. Ошбу эшләрне эшләүче Аллаһы сезнең Раббыгыздыр, барча галәмне тәрбияләүче Аллаһы бик бөек булды, мактау Аңа хастыр»* («Мөэмин сүрәсе», 64 аять).

Тулы бәхет - ул Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләне тануда, Аңа гыйбадәт кылуда, Аның кушканнарына буйсынуда. Шулай ук теләк һәм акылыбызның килешүе, Аллаһы Тәгаләне бар нәрсәдән өстен күреп, нәфесебезне буйсындыруда да. Шулардан кала, бернәрсә дә тулы бәхет бирә алмый, алар барысы да вакытлыча гына бирелгән рәхәтлек хисләре. Бу дөньяда бар тереклеккә дә тулы мәгънәсендә бәхет бирә торган сыйфатлар бирелмәгән, ә адәм баласына тумыштан ук шундый сыйфатлар бирелгән, бу - Аллаһы Тәгаләгә ышану, тәкъвалык, ярдәмчелек, Аллаһы өчен үз гомерен дә бирергә әзер булу. Шушы дөньяга килү белән үк адәм баласы бәхетле булырга тели һәм гел бәхетле булып яшисе килә. Башта бала өчен анасын күрү бәхет булса, соңыннан - анасы аны ашатып, аның белән бергә уйнавы бәхет күрә. Бала үскән саен, бәхет хисләре арта бара: курчак алсалар, машина, кәнфит, велосипед һәм теләкләрен үтәгән саен үзен бәхетлерәк хис итә бара. Әгәр дә ана үз вакытында балага вакытлы рәхәтлек хисләрен һәм чын бәхетле иткән хисләрне аерырга өйрәтмәсә, бала нәфесе теләкләренә иярәчәк. Шуның өчен ана кеше өстендә бик зур бурыч ята. Балага тулы бәхеткә алып барган яхшы сыйфатларын үстерергә ярдәм итәргә һәм Аллаһы кушкан яхшы гамәлләрне аңлатырга кирәк була. Шул чакта гына бала бәхетле гомер итә алачак.

Адәм баласы тумыштан бирелгән яхшы сыйфатлар белән гамәл кылса гына, тулы бәхеткә ирешәчәк. Кеше яхшылык эшләгән саен аның җанына рәхәт иңә, һәм ул үзен бәхетле хис итә башлый. Андый хисләрне берәр кешегә бүләк бирсәң, кайгылы вакытында тынычландырсаң, ач кешене ашатсаң, бар нәрсәгә өмет өзгән кешегә ярдәм кулын сузсаң, ягъни бар тереклеккә ярдәм итсәң генә кичерергә була. Шул вакыт кешенең күңелендә рәхәтлек һәм тулы бәхет хисләре туачак.

Аллаһы Тәгалә безгә тумыштан ук бәхетле итә торган хисләр белән беррәттән, начар, безне тормышыбызда сыный торган сыйфатлар да биргән. Сынау үткәндә, шул начар сыйфатларны вакытында танып, алар аркасында эшләнә торган начар гамәлләрдән сакланып калырга кирәк. Нәтиҗәдә без Аллаһы Тәгаләгә буйсынуыбыз аркасында бәхет хисләре тоя башлыйбыз. Бу дөньяда яхшы күренгән тормыш, төрле нигъмәтләр, мал-мөлкәтләр кешегә кыска вакытлы гына рәхәтлек хисләре бирә. Акыллы кеше Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгаләне танып, яхшы гамәлләр кылып, уңай сыйфатларын үстереп, барлык нигъмәтләрне Аллаһыдан икәнлеген аңлап, чын бәхеткә ирешә. Язмышына карата кеше төрле сынаулар аша үтә: якыннарын югалта, бәла-казалар, гаделсезлек, явыз кешеләрнең рәнҗетүләрен кичерә. Шул сынауларны тиешлечә, сабыр итеп үткәрсә, кеше бәхеткә лаек була, инша Аллаһ. Бәхетне саклап калу өчен, адәм баласының күңелендә иманы көчле һәм нык булырга тиеш. Бу дөньяда төрле сынаулар, кыенлыклар үткән саен, Аллаһының мәңгелек җәннәтенә юл тотканда, без үзебезне тагы да бәхетлерәк тоя башлыйбыз, һәр гамәлебезне башкарганда, Аллаһы Тәгаләне исебездә тоту зарур. Дини гыйлем алып, шул гыйлемне йөрәк аша үткәреп, аны тормышка ашыра алсак, Аллаһыга карата ышанубыз арта барыр, ә ышану белән беррәттән бәхеткә дә ирешербез.

Кеше һәрвакыт бәхеткә омтыла. Төрле гасырларда бәхет турында шигырьләр язылган, җырлар җырланган, хәтта бәхеткә ирешәм дип явызлык та кылынган. Ләкин Аллаһыны онытып, явызлык кылган саен, кеше бәхет хисен югалта, аны вакытлыча гына булган рәхәтлеккә алмаштыра. Һичкем дә явызлык кылып бәхетле була алмый. Шуңа күрә без, дини гыйлем алып, иманыбызны камилләштерик. Аллаһы Тәгаләгә ышанмаган адәм баласы ике дөнья бәхетеннән дә мәхрүм була.

Коръәни-Кәримдә: *«Ий мөэминнәр, Аллаһыдан куркыгыз, Аңа гөнаһлы булудан сакланыгыз, вә һәркем ахирәт өчен кылган гамәлләрен тикшереп карасын, һәркем үлем килмәс борын иманын, динен төзәтсен, вә Аллаһы газабыннан сакланыгыз, бит Аллаһы сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдардыр», диелә* («Хәшер сүрәсе», 18нче аять).

**Җәмил хәзрәт ХАЛИТОВ.**

*("Иман" газетасыннан)*

№ 18 (1145), 28 апрель 2012 ел
Бердәмлек